| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Буа шәһәре **КАРАР**

19.09.2026 № 333/Бк/к

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй» балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениесе уставын яңа редакциядә раслау турында

Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 52 статьясына таянып, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон (25.04.2026 редакциясендә), «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәве турында» 2001 елның 08 августындагы 129-ФЗ номерлы 129-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Уставы нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенең гамәлгә кую документларын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе уставын яңа редакциядә (әлеге карарга 1 нче кушымта) расларга.
2. Әлеге карарның 1 пункты белән расланган Устав «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 08 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәвенә алынган көннән үз көченә керә һәм ул үз көченә кергәннән соң барлыкка килгән мөнәсәбәтләргә карата кулланыла дип билгеләргә.
3. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй» муниципаль бюджет мәктәпкәчә мәгариф учреждениесенең әлеге карар белән расланган Уставы үз көченә кергән көннән, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй»

муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе уставын, аңа алга таба үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, раслау турында Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 06 сентябрендәге 257 /Бк/к номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Бикмураз авылы катнаш төрдәге мәктәпкәчә белем бирә торган «Миләшкәй» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдиренә:

әлеге карар белән расланган Уставны Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 8 нче районара инспекциясендә әлеге карар кабул ителгән көннән алып бер ай эчендә дәүләт теркәвен тәэмин итәргә;

дәүләт теркәвеннән соң «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУнә һәм «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлегенең мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУнә дәүләт теркәве турында салым органы тамгасы белән Уставның таныкланган күчермәсен тапшырырга;

дәүләт теркәвенә алынган көннән алып 30 көн эчендә педагогик хезмәткәрләрне, башка хезмәткәрләрне һәм тәрбияләнүчеләрнең ата-аналарын (законлы вәкилләрен) яңа редакциядәге Устав белән имза салып таныштырырга;

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 29 статьясы таләпләре нигезендә уставны яңа редакциядә учреждениенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.;

учреждениенең үз көчен югалткан уставка сылтама ясаган локаль норматив актларына тиешле үзгәрешләр кертергә.

5. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (http://buinsk.tatarstan.ru/) урнаштырылырга тиеш.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Буа муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгына йөкләргә (Македонская Н.А.).

Буа муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Л.Р. Шакирҗанов